БӘХЕТЛЕ ШАГЫЙРЬ

Роберт Миңнуллин яшәгән йортта истәлек тактасы ачылды

> 2

БЕТМӘС БУРЫЧ

Язучы гомер буе халыкка хезмәт итәргә тиеш дигән фикер дөресме?

> 3

ЧИЯЛЕКТӘ КҮРГӘННӘР

Кәрим Хәбиев бакчасында 300дән артык үсемлек һәм куак үсә

> 4

ИГЕЛЕКЛЕ ТАТАРСТАН

Республикада волонтерлар өчен бәйге башланды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 129 (28902) | Сишәмбе | 6 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

УКЫТЫРГА – УКЫТУЧЫ, ДӘВАЛАРГА ТАБИБ КИРӘК

ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНДАГЫ ВАЗГЫЯТЬ

Республикага «ак яка»лар түгел, машина йөртүчеләр, пешекчеләр, эретеп ябыштыручылар, электриклар, программистлар, инженерлар кирәк. Шулай ук укытучыларга, табибларга да ихтыяҗ зур. Иң күп хезмәт хакы файдалы казылма чыгаручылар һәм IT белгечләргә туры килә. Аларның хезмәт хакы – 60 мең сум. «ВТ» хәбәрчесе хезмәт базарындагы вазгыятьне белеште.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан узган ел хезмәт базары нәтиҗәләре буенча илнең лидер төбәкләре бишлегенә керде. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан буенча төбәк органы мәгълүматларыннан күренгәнчә, республикада эшсезлек дәрәҗәсе кимегән. Хәзер ул 0,51 процентны тәшкил итә. Эшсезлек күрсәткече иң түбән районнар – Минзәлә (0,20%), Лаеш (0,21), Ютазы (0,23) һәм Яңа Чишмә (0,23). Питрәч районы исә эш эзләүчеләр буенча беренче урында (0,69 процент) тора. Моннан тыш, иң зур күрсәткечләр Теләче, Әлмәт, Мөслим районнарында теркәлгән.

Росстат мәгълүматларына караганда, Татарстанда уртача хезмәт хакы 52789 сум тәшкил итә. Бу – узган ел белән чагыштырганда, 15,3 процентка артыграк дигән сүз. Иң югары хезмәт хакы файдалы казылмалар чыгару (72800), мәгълүмат технологияләре (67300) һәм финанс (61000) өлкәсенә туры килә. Иң түбән хезмәт хакын медицина хезмәткәрләре (43800), укытучылар (36600) һәм сатучылар (34600) ала.

Белгечләр базарындагы вазгыятьне белешү өчен, Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать иттек. Министрлыкның матбугат үзәге хәбәр итүенчә, хәзерге вакытта хезмәт базарында хәл тотрыклы санала. 23 августка китерелгән саннарга караганда, Татарстанда эшсезләр – 10 384 кеше. «Россиядә эш» порталында төрле һөнәрләр буенча 75 мең буш урын тәкъдим ителә. Республикада укытучылар, табиблар, төзүчеләр, машина йөртүчеләргә ихтыяҗ бар.

– Бүген сәнәгать предприятиеләрендә эшләүче кадрларга сорау зур, инженерлар да бик кирәк. Хезмәт базарындагы 75,2 мең вакансиянең 42 проценты сәнәгать җитештерүенә туры килә. Бу – эшкәртү сәнәгате, металл эшкәртү, машина төзелеше. Оборона предприятиеләре дә эшче көчләргә ихтыяҗ кичерә. Фрезеровщик, станокта эшләүче, оператор, слесарьлар кирәк. Яңа уку елы башлану белән укытучыларга да ихтыяҗ арта. Табиблар, медицина хезмәткәрләре дә кирәк, – диде министрлыкның матбугат үзәге җитәкчесе Рафаил Гыйниятуллин.

Россиядә IT хезмәткәрләргә ихтыяҗ кимегән. РБК ел башыннан Россиядә IT өлкәдә эшләргә вакансияләр санының 25 процентка кимүе турында яза. Белгечләр мондый вазгыятьне базарда онлайн курсларда әлеге һөнәрне үзләштергән яшь белгечләр күбәю белән аңлата. Бу чыннан да шулаймы? Әлеге сорауга Татарстан Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы ачыклык кертте.

– IT белгечләр хезмәт базарында ихтыяҗ аеруча зур булган унлыкка керә. Татарстанда төбәкләрдәге компанияләр зур ихтыяҗ кичерә. IT тармак өчен кирәгеннән артык белгеч булуның куркынычы юк. Республикага бу индустрия белгечләре һәрвакыт күп кирәк, – диделәр матбугат үзәгендә.

Бүген эш табу җиңелме? Эш эзләүчеләргә нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килә?

– Улыбыз Гадел көз көне армиядән кайтты. Хәрби хезмәттән кайтучыларга дүрт ай буе унар мең сум акча биреләсен ишеткәч, социаль яклау бүлегенә бардык. Биржага басса да, эшне үзебез таптык. Озак аптырап йөрергә туры килмәде. Гадел йөк ташу буенча логистлыкка укыган иде. Ләкин үз юнәлеше буенча эш булмады, газ оешмасына слесарь булып урнашты. Ай саен 20–24 мең сум акча ала. Читтән торып укый да әле. Дәүләт оешмасы булгач, укыган вакытта өстәмә акча да түләнә, бик теләп эшли, – ди Казанда яшәүче Миләүшә Галиева.

Башкалада яшәүче ике бала әнисе Зөбәрҗәт Мәгъзүмова эш эзли. Сайланып тормый, теләсә нинди эшкә урнашырга да риза. Һөнәре буенча хисапчы ул. Ләкин хезмәт хакы аз булгач, аннан киткән булган. «Минем өчен хезмәт хакы беренче урында тора. Акча булмаса, беркая да барып булмый бит. Шуңа күрә төшемле эш булсын иде инде ул. Эзләгән кешегә эш табу проблема түгел», – диде Зөбәрҗәт Мәгъзүмова.

Ләйсән САФИНА

НИНДИ БЕЛГЕЧЛЕКЛӘРГӘ ИХТЫЯҖ АРТКАН?

Җитештерү өлкәсе – 42,5% (32 мең эш урыны бар);
Төзелеш һәм күчемсез милек өлкәсе – 11,0% (8,3 мең);
Мәгариф һәм фән – 4,9% (3,7 мең);
Транспорт – 4,8% (3,6 мең);
Сәламәтлек саклау – 4,3% (3,2 мең);
Азык-төлек сәнәгате – 4,2% (3,1 мең);
Сату – 3,9%, көнкүреш хезмәте күрсәтү (2,9 мең);
Консалтинг – 3,3% (2,5 мең);
Башка өлкәләр – 21,2% (15,9 мең).

Халыкка якынрак

Дәүләт һәм җирле үзидарә органнары «Одноклассники» һәм «ВКонтакте» социаль челтәрләрендә үз сәхифәләрен алып барырга тиеш. Россия Хөкүмәте шул хакта карар чыгарды. Аны Премьер-министр Михаил Мишустин имзалады.

Әлеге карар бу елның 1 декабрендә үз көченә керә. Рөхсәт ителгән ике ресурста – «Одноклассники» һәм «ВКонтакте»да рәсми органнарның эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштырылырга тиеш.

«Аерым алганда, сүз уздырыла торган чаралар турында хисап, актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар, электрон почта адресы һәм телефон номерларын урнаштыру турында бара», – дип хәбәр ителә Россия Хөкүмәте сайтында.

Ял көннәре билгеле

Яңа уку елында мәктәп укучылары өчен каникул көннәре билгеле булды.

Шулай итеп, мәктәп балалары көзге каникулга 29 октябрьдән чыгып, 6 ноябрьгә кадәр ял итәчәкләр. Кышкы яллар 31 декабрьдән 8 гыйнварга кадәр сузылачак. Язын балаларга 8 апрельдән 16сына кадәр ял булачак.

«Төрле төбәкләрдә ял расписаниесе аерылырга мөмкин, мәктәп администрациясе ял вакытын үзе хәл итәргә хокуклы», – дип аңлатканнар «Объясняем.РФ» порталында.

Искәртеп үтик: көзге каникул вакытына Халыклар бердәмлеге көне – дәүләт бәйрәме туры килә, ул 4 ноябрьдә – җомга көнне билгеләп үтелә. Шулай итеп, Россиядә яшәүчеләр өч көн рәттән – 4–6 ноябрьдә ял итәчәк. Кышкы каникул Россиядә Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан ял көннәре белән тулысынча туры килә һәм тугыз көн дәвам итә.

Күтәрелгән ярминкәләр

10 сентябрьдә Казанда традицион көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләре башлана. Башкаланың Кулланучылар базары комитеты рәисе Руслан Фазылҗанов сөйләвенчә, авыл хуҗалыгы ярминкәләре һәр шимбә шәһәрнең алты районындагы 15 мәйданчыкта, Салават Күпере халкы өчен «Радужный» сәүдә үзәге янындагы парковкада узачак. Ярминкәләр 24 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.

«Ярминкәдә халык өчен яшелчә, ит продукциясе тәкъдим ителәчәк, шулай ук көнкүреш кирәк-яраклары да сатылачак», – диде ул. Ярминкәләрдә товарларны республиканың 22 районы һәм 18 агросәнәгать оешмасы вәкилләре сатачак.

Руслан Фазылҗанов Юдино бистәсендәге Революция урамында яңа чатыр мәйданчыгы төзелүен дә искәртте. «Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов карары һәм Казан мэры Илсур Метшин ярдәме белән биредә яңа асфальт катламы, барлык уңайлыклары булган ярминкә чатырлары, павильоннар барлыкка киләчәк», – диде ул.

Актуаль тема

Тикшергәч ышанасы

Якын киләчәктә банклар шикле счетларга акча күчерүне ике көнгә туктатып торырга мөмкин. Депутатлар гамәлдәге законга шундый төзәтмә әзерләгән.

Проект авторы – Россия Дәүләт Думасының Финанс базары буенча комитет башлыгы Анатолий Аксаков фикеренчә, бу яңалык гамәлгә керә калса, мошенниклар тарафыннан алданучылар саны бермә-бер кимеячәк.

Ник дигәндә, аның нигезендә банклар, шикле счетларга акча күчерергә маташканнарын ачыклауга, бу операцияне ике көнгә туктатып торырга тиеш. Шушы вакыт эчендә банк бу счетны мошенниклар тарафыннан кулланылган ялган счетлар базасына кертеп тикшереп карый, аздан гына алданмаган кеше исә акчасын саклап кала ала. Шикле счетка акча күчүгә ирек куйган очракта, мошенниклар урлаган акчаны иясенә банк үзе кайтарырга мәҗбүр булачак.

Гамәлдәге закон нигезендә банклар клиентларының урланган акчаларын кайбер очракларда гына кире кайтара ала. Әйтик, әгәр банк кешене аның исәп-хисап счеты белән шикле операция башкарулары турында кисәтмәгән булса, ул бу акчаларны үзе түләргә тиеш. Кеше нindидер операцияне аның ризалыгыннан тыш башкарулары турында хәбәр итә торып та, банк мошенникларга акча күчерүен дәвам иттерсә, югалган акчаны шулай ук кредит оешмасы кайтарырга тиеш.

Мошенникларның оста психолог булуы, нинди алымнар ярдәмендә алдавы турында даими сөйләп торалар. Әмма шуңа да карамастан, алданучылар кимеми. Әле узган тәүлектә генә Татарстанда яшәүчеләр кырыгалдарларга 5,8 миллион сумнан артык акча күчергән. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, бер көн эчендә Казан, Бөгелмә, Алабуга һәм Лениногорск шәһәрләрендә яшәүчеләр әнә шулкадәр акчасыннан колак каккан. Үзәк банк мәгълүматларына караганда, узган ел Россиядә 13,58 миллиард сумлык шикле операцияләр теркәлгән. Алар, нигездә, кешеләрнең беркатлылыгы, мошенникларга бар кирәкле мәгълүматны әйтеп бирүләре аркасында килеп чыккан. Кеше ризалыгыннан тыш башкарылган шикле операцияләрдә югалган акчаның нибары 6,8 процентын гына кайтара алганнар.

Шуңа күрә белгечләр гади генә саклык кагыйдәләрен тагын бер кат халыкның исенә төшерергә мәҗбүр. Банк хезмәткәрләре беркайчан да клиентларының шәхси мәгълүматларын сорап, йә булмаса, акчаңны югалтуың бар, дип куркытып шалтыратмый. Алар клиентның банк картасы номерларын, смс аша килгән парольләрне дә сорамый. Гомумән, үзегез турындагы шәхси мәгълүматны, банк картасы номерларын, смс аша килгән кодларны беркемгә дә хәбәр итмәгез. Мошенник корбаны булмас өчен, иң элек 112 номерына яки «ышаныч телефоны»на шалтыратып, теге яки бу номер буенча сезгә кем шалтыратканны, ул сөйләгән сүзләрнең дөресме-юкмы икәнлеген белешергә кирәк. Телефонга килгән шикле сылтамаларга да басмагыз.

Сүзгә-сүз

Сергей ГЛАГОЛЕВ, Россия сәламәтлек саклау министры урынбасары:

Сирәк очрый торган авыруларны дәвалау өчен препаратларның өчтән икесе хәзерге вакытта чит илләрдән сатып алына. Шундый 189 даруның аналогларын үзебездә булдыра башлаячакбыз. Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә кирәкле препаратлар исемлеге төзелде. Бүген үзебездә рөхсәтсез җитештерә алмаганнарына патент алу мәсьәләсе дә хәл ителә.

(«Инновационная онкология» форумында сөйләгәннәрдән)

ТАТАРСТАНДА – АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

Гыйнвар – июль айларында Татарстанда авыл хуҗалыгы оешмалары, крестьян һәм фермер хуҗалыклары, шәхси хуҗалыклар барлыгы 126 миллиард сумлык продукция җитештергән.

932,4 мең баш мөгезле эре терлек >> – 3,9%↓
340,1 мең баш кәҗә һәм сарык >> – 2,5%↓
512,3 мең баш дуңгыз >> – 0,3%↓
19,6 миллион кош >> +0,6%↑

Сентябрь салкын алып килде

Бу атнада Татарстанда суык һава торышы булачак, яңгыр да явачак. Бу хакта республиканың гидрометеорология үзәге белгечләре хәбәр итә. Аларның фаразы буенча, һава температурасы нормадан 6–7 градуска түбәнрәк булачак.

Төнлә Татарстанда температураның +1...+6 градуска кадәр төшүе көтелә. Кайбер урыннарда 1 градуска кадәр кырау булуы да ихтимал. Сишәмбе исә һаваның максималь температурасы +10...+15 градус булыр дип көтелә.

Чәршәмбе төнендә һәм пәнҗешәмбедә Татарстанда температура +2...+8 градус чамасы булыр дип фаразлана. Көндезге температура +9...+14 градустан артмаячак.

Синоптиклар сүзләренчә, бу атна җомгасы һәм шимбәсендә яңгырлы һәм суык һава торышы көтелә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КВОТА БУЕНЧА ҖЫЛЫНУ

Үткән елларда Европа илләренең байтагында халыклар утка-җылылыкка бәяләр күтәрелүгә протест белдереп, урамга чыкты, рәсми хакимиятләрнең отставкасы таләп ителде. Баш күтәрүчеләр Германиядә Украинага ярдәм итүне туктатуны, Россия белән газ мәсьәләсендә сөйләшүләр өстәле янына утыруны таләп итте. Кызыгы шунда: Европаның иң куәтле икътисады Киевка ярдәмне бик чамалап кына тамыза, әмма Мәскәү белән барыбер уртак тел таба алмый. Кремль «Төньяк агым»ны башта тикшерүгә туктатып, аннан торба ватык дигән сылтау белән бөтенләй кранны ябып, август ахыры – сентябрь башында Көнбатышны ярыйсы гына интектерде. Европадан: «Газпром» – килешүләрне үтәми торган, ышанычсыз партнер», – дип рәсми белдерүләр яңгырады. Бу ике як өчен дә начар вазгыять: европалыларга газ дефициты яный, Россиягә мөһим базарны югалту белән куркыныч. Кытай, Россиядән алган газны сыекландырып, Европага озата. Аңлашыла инде: түбән бәягә ала, кыйммәткә сата. Планетада сәер газ әйләнеше барлыкка килә. Халыкларның сәясәтчеләрнең тәкәбберлегендә, амбицияләрендә эше юк. Кешеләргә арзанлы ягулык кирәк. Чехиядә 70 мең кеше урамга чыкты. Европа илләренең рәсми хакимиятләре, ял көннәре протестын Мәскәү оештырды, дип баралар. Италиядә халык ягулыкка түләү квитанцияләрен урамга алып чыгып яндыра. «Без түләмибез һәм хәзер хаос булачак!» – диләр.

«Ягулык фетнәсе» бер Европада гына түгел, Җир шарының башка почмакларында да бара. Индонезиядә – газ экспортлаучы илдә – урамга чыккан халыкны рәхимсез рәвештә куып тараттылар. Колорадода Xcel Energy коммуналь компаниясе «акыллы термостатлар»ны читтән торып шундый итеп көйләп куйды: өйләрдәге температура хәзер 25,5 градустан да түбәнәйми. Әлегә анда җылыту түгел, суыту – проблема, чөнки штатта гадәттән тыш эсселек. Кондиционерлар чыдамый. Электрны күп тоту сәбәпле, электр челтәрләре эштән чыгарга мөмкин. Европада эш шуңа барып җитте: андрон коллайдерны туктатып, энергия сакламак булалар. Англиядә заводларның 60 проценты, электр бәяләрен күтәрә алмыйча, ябылу алдында тора дигән ышанычлы хәбәрләр бар.

Көнбатыш хөкүмәтләре үз халыкларын бөлгенлеккә төшүдән саклау юлларын эзли. Ач-ялангач халыкның урамнарга чыгуы рәсми хакимиятләрне бер дә сөендерми. Германия, электр бәяләрен компенсацияләү өчен, 65 миллиард евро әзерләп куйды. Акчаны халыкка түгел, электр сатучы компанияләргә бирергә ниятлиләр. Соңгылары халыкка утны түбән бәядән сатарга тиеш була. Австриядә һәр өлкән кешегә – 500, балаларга 250 евро акча өләшмәкчеләр. Нидерландта «углерод янчыклары» кертү идеясе калкып чыкты. Һәр кешегә углерод лимиты булдырмакчылар. Зур йортта яшәп, күп газ ягасың икән, җылыда яшисең килсә, кечкенә йортта яшәп, газны аз ягучы күршеңнең лимитын сатып аласың. Самолетларда еш очучылар белән дә шулай хисап ясарга телиләр. Күп очасың икән, очкычка утырасың килсә, бер дә очмаган, яисә аз очкан илдәшеңнең лимитын сатып алырга туры килә. Шундый заманнар җитте: кайбер илләрдә шәм яндыра башладылар. Польшада, кино карау өчен, энергияне тәгәрмәчне педаль белән әйләндереп табалар. Сәламәтлеккә дә файдалы, электр да янга кала.

Россиядә

ЮАНЬНЫ КЫТАЙ РӨХСӘТЕ БЕЛӘН ТОТУ

Россиянең төп икътисади проблемалары да нигездә углеводород базары тирәсендә барган гаугага бәйле. Океан артында безнең нечкә җирне яхшы беләләр: нефть һәм газ сатуны чикләп кенә калмыйча, аларны түбән бәядән, хәтта бушка алу хәстәрен күрәләр. «Российская газета» дүшәмбе санында «Как ценовой потолок на российскую нефть и газ изменит мировой рынок энергетики» дигән язма бирә. Көнбатыш инде декабрьдән – Россия нефтен, февральдән нефть продуктларын үзләре куйган «түшәм» бәядән генә сатарга рөхсәт итәргә дигән карарны чыгарып куйды. Мәскәүдәге югары хакимиятләр кемдер мәҗбүри куйган бәягә буйсынмаячакларын әйтәләр. Вице-премьер Александр Новак, мәсәлән, бәяне түшәмгә терәгән дәүләтләргә Россия нефте сатылмаячагын кистереп әйтә. Кытай һәм Һиндстан безнең «кара алтын»ны алырлар дигән өмет белдерелә. Углеводород базары белгечләре дә шул фикерне куәтли. ОПЕК илләре бу мәсьәләдә Россия яклы. Нефть сатучы илләр буларак алар аңлыйлар: бүген Россияне түшәмгә терәсәләр, иртәгә башка илләрне буйсындырачаклар.

Мәсьәләгә шулай да ваемсыз карарга ярамый. Көнбатышта бик астыртын сәясәтчеләр утыра, алар ни эшләгәннәрен белеп эшли. Санкция кертелгән икән, аның кыршавы эченнән чыгу бик кыен, хәтта мөмкин түгел диярлек. Бөек держава булган Кытайның Weichai Power компаниясе, әйтик, КамАЗга газ двигательләрен сатуны туктатты. Корпорация өчен бу – зыянлы адым, әлбәттә. Базарны югалту – табышны югалту. Әмма Пекинның рәсми хакимиятләре үз җитештерүчеләренә санкция астындагы предприятиеләр белән эшләмәскә куша.

Нефть белән дә шулай булмас дип кем әйтә ала? Бүген үк ике зур дәүләт – Кытай белән Һиндстан Россия нефтен алуны киметә башлады. Моның ике сәбәбе бар. Берсе – Вашинтон чиновниклары бик еш ике башкалага оча, аеруча Дәһлигә нефть мәсьәләсендә зур басым ясыйлар. Икенче сәбәп: нефть заводлары аерым сорт нефтьне эшкәртүгә көйләнгән. Россиянең авыр нефтен эшкәртү өчен, алардагы җиһазларга үзгәреш кертү таләп ителә. Бу – финанслар сорый торган мәшәкать. Санкцияләр астындагы ил нефтенә завод үзгәртеп кору – өметсез эш. Син үзгәрешләр кертерсең, ә нефтьне бөтенләй тыярлар.

Кытай базары белән чикләнү – Россиянең үзе өчен дә хәвефле эш. Товарыңны юаньга сатарга туры киләчәк. Юань – даими рәвештә кыйммәтен югалтып торучы «йомшак» валюта. Әмма эш анда гына да түгел. Кытай акчасын тотам дисәң, Пекин белән аерым килешү төзелү сорала. Россиянең Үзәк банкы яңа гына шундый презентация эшләде. Презентациядә юаньны тоту өчен Кытай рөхсәтен алу бик катлаулы эш икәнлеге әйтелә. Димәк, Кытай акчасына нидер сатсаң, бушка сатасың. Хәер, хәзер Көнбатышка сатсаң да шул ук хәл инде. Россия – үз резервларында иң күп юань тотучы ил һәм ул акча хәзер куркыныч астында.

БӘРӘКӘТЛЕ НЕФТЬ

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ӘЛМӘТКӘ СӘФӘР КЫЛДЫ

tatarstan.ru

Узган шимбәдә нефтьчеләр һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтте. «Кара алтын» төбәге буларак танылган Әлмәт шәһәрендә бу көнне тантаналы чара узды. Нефтьчеләрне котларга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та килгән иде. Аңа кадәр Президент Әлмәттәге «Адымнар» мәктәбендә, төзекләндерүдән соң ачылган сәнгать мәктәбендә, Ризаэддин Фәхретдин исемендәге бульварда булды.

Рөстәм Миңнехановның эшлекле сәфәре Әлмәтнең «Адымнар» полилингваль мәктәбеннән башланды. Республикада ачылган шундый күптелле мәктәпләрнең алтынчысы бу. 2021 елның сентябрендә төзелә башланган мәктәп быел 1 сентябрьдә тәүге тапкыр укучылар кабул итте. Анда 800ләп бала укыячак. Әлеге алдынгы мәктәптә укучылар рус, татар һәм инглиз телләрендә белем алачак. «Адымнар» мәктәбендә Рөстәм Миңнеханов уку сыйныфларын, ашханә, бассейнны карады. Президент балалар һәм укытучылар белән аралашты, аларны яңа уку елы башлану белән котлады.

Бу көн Әлмәт тарихында шатлыклы вакыйга белән дә истә калды. Шәһәрдә төзекләндерүдән соң сәнгать мәктәбе ачылды. Дүрт катлы бинада яңарту эшләре узган ел башланган. Сәнгать мәктәбенә яңа сулыш керткән «Татнефть» оешмасыннан хәбәр итүләренчә, иске бина сәнгать сөючеләрне сыйдыра алмаган. Яңа бинада исә 14 уку сыйныфы ачылган. Моннан тыш биредә медицина һәм сәнгать эшләре күрсәтелә торган бүлмәләр, методик фонд та эшли. Мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен лифт һәм санузеллар бар. Хәзер мәктәп барлыгы 1050 кешене кабул итә ала.

Яңа сәнгать мәктәбе ачылышында катнашкан Рөстәм Миңнеханов шундый зур эш башкарып чыкканнары өчен «Татнефть» оешмасына рәхмәт белдерде. «Оешма республика халкының тормыш сыйфатын күтәрү өчен күп нәрсә эшли. Өстәвенә бу эш Әлмәттә генә түгел, республикабызның башка шәһәрләрендә дә башкарыла», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әлмәткә эш сәфәре барышында Рөстәм Миңнеханов Ризаэддин Фәхретдин исемендәге бульварда да булды. Ул «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты кысасында төзекләндерелгән. Яңартылган бульвар җәяүлеләр өчен заманча күпфункцияле имин урын булдыруны күздә тота. Биредә гарәп язмасы һәм Ризаэддин Фәхретдин сүзләре язылган декоратив койманы күрергә мөмкин. Бульвар шартлы рәвештә 4 өлешкә: керү, балалар, спорт һәм Хәтер зоналарына бүленгән. Биредә яңа памп-трек та урнашачак. Анда сигез яше тулган балалар велосипед, скутер һәм роликларда йөри алачак. Моннан тыш бульварда панна-футбол өчен түгәрәк кыр да ачылачак.

Президентның Әлмәт шәһәренә эшлекле сәфәре Нефтьче көне уңаеннан уздырылган тантаналарда дәвам итте. Шәһәрдә, гадәттәгечә, махсус техника һәм хезмәт коллективлары вәкилләре парады, төрле мәйданчыкларда бәйге һәм концертлар узды. Рөстәм Миңнеханов исә «Татнефть» оешмасында хезмәт куючы яшь хезмәткәрләрнең һөнәри осталык бәйгесен күзәтте. Татарстан Президенты билгеләп үткәнчә, бәйгене шундый ачык һәм мавыктыргыч форматта уздыру нефтьче һөнәрен популярлаштырырга ярдәм итә.

Билгеле булганча, әлеге бәйге беренче тапкыр 1970 елда «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсендә нефть чыгару, скважиналарны җир астында ремонтлау, катлам басымын саклау цехларында узган. 1975 елдан аерым нефть белгечлекләре буенча ярышлар үткәрелә башлый. 1986 елда исә бу бәйге беренче тапкыр «Татнефть» берләшмәсе тарафыннан оештырыла. 2003 елдан бәйге яшьләр статусын ала, анда 35 яшькә кадәрге яшь хезмәткәрләр катнаша. Быел бәйгедә катнашу өчен 670 кеше гариза тапшырган. Шуларның 300е финалга үткән.

Хәтер биреме

Татарстанда Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышланган «Җиңү диктанты» халыкара патриотик акциясе узды. Казанда Бөек Ватан сугышы музей-мемориалында узган акциядә Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

«Җиңү диктант»ы республикада өченче, Россия һәм чит илләр буенча дүртенче тапкыр оештырылды. 2019 елда диктантны 24 илдән 105 мең кеше язган булса, былтыр – 80 илдән 1,5 миллион кеше. Халыкара тарихи диктант Бөек Ватан сугышын өйрәнүгә һәм халыкның тарихи белемен үстерүгә юнәлтелгән. Катнашучылар 45 минут эчендә Бөек Ватан сугышына бәйле 25 биремне үтәде.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, мондый чараларга ихтыяҗ зур.

– «Җиңү диктанты»н уздыру илебезнең күркәм традициясенә әверелде. Кызганыч, сугыш еллары чорының тарихи чынбарлыгы, кан-үлем белән күзгә-күз очрашкан ветераннарыбызның гамәлләре онытыла бара. Бу диктант белән җиңү өчен гомерләрен биргән әби-бабаларыбызга, тыл хезмәтчәннәренә олы хөрмәт күрсәтәбез. Шунысы сөендерә: катнашучылар саны елдан-ел арта бара. Безнең өчен сан да, сыйфат та, бу коточкыч сугышта катнашкан ветераннарыбызның батырлыкларын искә төшергән кешеләрнең күңеленә үтеп керү дә мөһим. Без үз тарихыбызны белү генә түгел, халкыбызга зур авырлыклар китергән сугыш вакыйгаларын истә тотарга, исән ветераннарыбызга һәм тыл хезмәтчәннәренә ярдәм күрсәтергә тиешбез. Бу диктантны язу – безнең бурычыбыз, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова быел республикада диктант язучылар саны 10 меңнән артык булачагын әйткән иде.

– Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы үзәк мәйданчык булып тора. Өченче ел рәттән диктантны шунда үткәрәбез. Бу – мәҗбүри түгел, ә йөрәк кушуы буенча башкарыла торган гамәл. Аеруча үсеп килүче буынга өметләр баглыйбыз. Дәһшәтле сугыш вакыйгаларын, аның кыенлыкларын үз җилкәсендә күтәргән әби-бабаларыбызны онытмасыннар иде, – диде Гөлнара Габдрахманова.

Диктант нәтиҗәләре 2022 ел ахырында билгеле булачак. Җиңүчеләрне, барлык сорауларга дөрес җавап бирүчеләрне Мәскәүдә уза торган Җиңү парадына чакырачаклар.

Ләйсән САФИНА

Финиш сызыгында

Татарстан 11 сентябрьдә узачак Бердәм тавыш бирү көненә тулысынча диярлек әзерләнеп беткән. Шушы көннәрдә типографиядә ике телдә 123 мең бюллетень бастырып чыгарылды. Республиканың Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев тавыш бирүгә әзерлек турында сөйләде.

Искәртеп узыйк: 11 сентябрь – Бердәм тавыш бирү көнендә илнең 81 төбәгендә (шул исәптән Татарстанда да) 4,6 меңгә якын участокта сайлау кампаниясе узачак.

Республикада Казанның ике округы буенча Дәүләт Советына депутат сайлау булачак. Тавыш бирүдә 123,1 мең кеше катнаша ала. Бу – республикада яшәүчеләрнең 4 проценты. Сайлауны 2 территориаль һәм 53 участок сайлау комиссиясе оештыра.

Моннан тыш, бердәм тавыш бирү көнендә җирле үзидарә органнары депутатларының өстәмә сайлавы узачак, алар Татарстанның 39 районындагы 181 округка кагылачак. Тавыш бирүне 42 территориаль һәм 177 участок сайлау комиссиясе оештыра. Сайлаучылар саны 51,2 мең кешене тәшкил итә. Җирле үзидарә органнарына депутатлыкка кандидат буларак 670 кеше теркәлгән.

Республиканың Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев сүзләренчә, парламентка өстәмә сайлау өчен 123 мең 700 бюллетень әзерләнгән. Ибраһимов сайлау округына 45 мең 870 бюллетень тапшырылса, Пионерлар сайлау округына калган 77 мең 830 тавыш бирү бланкы биреләчәк. Андрей Кондратьев искәрткәнчә, бюллетеньнәр ике телдә әзерләнгән. 9 сентябрьдә әлеге бюллетеньнәрне участок сайлау комиссияләренә таратачаклар.

Үзәк сайлау комиссиясе рәисе сүзләренчә, тавыш бирү куркынычсызлыкның барлык таләпләренә дә җавап бирәчәк. Монда сүз тышкы куркынычсызлык турында да, сәламәтлек турында да бара.

БӘХЕТЛЕ ШАГЫЙРЬ

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ЯШӘГӘН ЙОРТТА ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ АЧЫЛДЫ

Халык шагыйре Роберт Миңнуллинның исеме үзе яшәгән йорт диварында да мәңгеләштерелде. Әдип Казанда 2000–2020 нче елларда яшәгән Толстой урамы, 16А йортында истәлек тактасы ачылды. Әлеге чарада без дә булып кайттык.

shaimiev.tatarstan.ru

Зурлар өчен дә, балалар өчен дә кадерле шагыйрь иде. Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Роберт Миңнуллинны әнә шулай искә алды һәм аңа багышлап үзе язган шигъри юлларны укыды: «Әдәпле, зур йөрәкле, тыйнак, тирән фикерле. / Шундый шагыйрь Роберт безгә үрнәк түгелме? / Татар, башкорт халкына син Ходайдан зур бүләк! / Роберт иҗат чишмәсе эчеп туймас гаделлек».

– Аллага шөкер, безнең талантлы шагыйрьләребез күп. Ә Роберт иң талантлыларының берсе иде. Республикада ул алмаган бер генә әдәби премия дә калмады. Менә шундый иде Робертыбыз! Кешеләрне ярата белде, әйтеп бетергесез мәрхәмәтле иде. Һәр шигырен йөрәге аша үткәреп язды. Зурлар өчен дә, балалар өчен дә зур шагыйрь булды, барыбыз өчен дә якын иде. Без аның кебек шәхесләрне берничек оныта алмыйбыз, – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин күренекле әдипнең дәүләт эшендә дә алыштыргысыз кеше булганын әйтте.

– Аның кебек татар җанлы дәүләт эшлеклесе белән бер чорда эшләвем белән бик бәхетле мин. Ул үзе эшләгән катлаулы елларда Югары Советта да, Дәүләт Советында да алыштыргысыз кеше иде. Роберт Мөгаллим улының ялкынлы чыгышлары булган шикләрне таратты, дөрес юл күрсәтте. Ул һәрвакыт тиешле сүзләр таба белде. Бүген дә республика алар күрсәткән, алар билгеләгән юлдан бара һәм уңыш артыннан уңыш яулый, – дип сөйләде ул.

Аның халык өчен башкарган гамәлләре әле дә хәтердә. Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла шулай ди.

– Роберт Миңнуллин – иҗтимагый тормышыбызда зур роль уйнаган кеше. Кайчандыр Тукай: «Мин коеп куйган шагыйрь генә түгел, мин – сәясәтче дә, дипломат та, җәмәгать эшлеклесе дә», – дип язган. Бу сүзләр нәкъ Роберт Миңнуллинга туры килә. Балалар шагыйре булып танылса да, аның иҗтимагый эшләрдәге казанышлары әле дә исебездә. Суверенитет яулаган чордагы ялкынлы чыгышлары әле дә хәтердә. Роберт Миңнуллин Балалар фонды җитәкчесе булды, телевидение аша татар әдәбиятын пропагандалады, әдәбиятта беренче адымнарын ясаучы яшьләрнең язмышы белән кызыксынды, алар өчен чын күңелдән борчылды, – диде ул. – Кеше хәтере чикле, шуңа да кайберәүләр онытыла бара. Ләкин һич онытылмас шәхесләр дә була. Роберт Миңнуллин – әнә шундыйлардан. Нинди генә хәлләргә тарысак та, күз алдына аның мыек астыннан елмайганы килеп баса. Онытылмасын һәм онытылмас та!

Роберт Миңнуллинның якын дусты, Тукай премиясе иясе Рәдиф Гаташ чыгышын шагыйрьнең «Бәхетле булыгыз» шигырен укудан башлады.

– Робертның тәүге китабы «Бәхетле булыгыз» дип атала. Ул үзе дә бәхетле шагыйрь булды. Иҗатта да, тормышта да, – диде ул. – Аның бер юбилеенда Әмирхан Еники: «Роберт, без сине бик хөрмәт итәбез, дәрәҗәләреңне беләбез. Ләкин без, беренче чиратта, шагыйрьгә таянабыз, шагыйрьне яратабыз», – дигән иде. Менә без дә, якын дуслары, аның шагыйрьлеген мактыйбыз, яратабыз һәм сагынабыз. Ул бөтен халыкның йөрәген гади, әмма бар кеше өчен дә газиз сүзләр, төшенчәләр белән яулап алды. Әнкәйләргә мәңгелек һәйкәл куйды, киләчәк турында уйлап, балалар өчен иҗат итте, гел алар тирәсендә булды, туган ягын мәңгеләштерде.

Роберт Миңнуллинның тормыш иптәше Клара ханым исә барлык якыннары, туганнары исеменнән шагыйрьне онытмаулары өчен рәхмәтен белдерде.

– Робертыбызны шулай зурлап, яратып килгәнегез өчен зур рәхмәт! Аның арабыздан киткәненә өч ел булып килә. Шул вакыттан бирле Робертны бер генә секундка да онытканыбыз юк. Сагынабыз, юксынабыз… Робертны әбиләр дә, бәбиләр дә яратты. Ул берәүгә дә елмаюын кызганмады. Халыкка бик якын булды. Аны шуңа да яраталардыр, дип уйлыйм мин. Әлеге истәлек тактасын куярга да күршеләребез тәкъдим итте. Кирәкле имзаларын җыеп, тиешле урынга хәбәр иттеләр. Рәхмәт аларга! Робертның шигырьләре укылса, җырлары җырланса, исеме телгә алынса, без бик шат инде, – диде ул.

Истәлек тактасын яшь сынчы, Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы Тимофей Тюрин ясаган. Әдипнең кызы Таңсылу Сабирова исә аңа ярдәм иткән. Бронзадан булса да әтисенең нурлы күзләрен чагылдыруларын теләгән ул.

– Әлеге истәлек тактасын бер ел дәвамында бик тәфсилләп, һәр деталенә игътибар биреп эшләдек. Килеп чыкты кебек. Истәлек тактасының әтинең соңгы 20 елы узган йортка куелуына бик сөенәбез. Әлеге йорт артында бер тыкрык бар. Ул көн саен шунда йөреп кайта иде. Сәламәтлек өчен файдалы, дип чыгып китсә дә, иҗат турында уйлагандыр ул. Әтинең иң асыл иҗат җимешләре дә нәкъ шушы йортта яшәгән елларда дөнья күрде, дип беләм мин, – диде ул безгә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АНАТОЛИЙ ИВАНОВ:

«ЭШЛӘРГӘ ТЕЛӘГӘН КЕШЕГӘ МӨМКИНЛЕК БИРЕРГӘ КИРӘК»

Мамадыш күзгә күренеп үзгәрә, елдан-ел матурая һәм үзенә кунакларны җәлеп итә. Республикада беренчеләрдән булып Нократ елгасы яр буйларында ял итү өчен урыннар булдырган район ул. Терлекчелектә, игенчелектә, умартачылыкта, хәтта җәнлек үстерү буенча да даны еракларга таралган. Уңыш сере нидә соң? Мамадыш районы башлыгы Анатолий ИВАНОВ белән район тормышы, андагы үзгәрешләр, киләчәккә планнар турында сөйләштек.

:: Анатолий Петрович, район көннән-көн матурлана. Моннан 5 ел элеккеге сукмакларны да танып булмый хәтта. Җитәкче буларак, каян шулкадәр көч һәм дәрман аласыз?
– Җитәкче урында хезмәт итү зур җаваплылык өсти. Ә инде бөтен районны идарә итү өчен, үзеңне кызганмаска, бар тормышыңны эшеңә багышларга кирәк. Соңгы 90 елда Мамадышта 20 җитәкче булган. Шулар арасында бер мин – шушы район кешесе. Үз халкыма хезмәт итүемне зур бәхеткә саныйм. Әгәр башка җирдә булсам, моның кадәр эшләр идемме икән, дип тә уйлыйм. Мамадыш өчен барысын да эшләргә тырышам. Юк нәрсәләрне бар итеп, әллә нинди программалар табып, районы яхшыртасы, үзгәртәсе килә бит. Тагын шул ягы бар: кайда гына хезмәт куйсаң да, җаваплылык зур. Район җитәкчесе үз җирлегендә эшләгән һәр оешма хакында белергә тиеш. Бергәләп эшләгәндә, уңышка ирешеп була.

Мамадыш – республиканың иң зур районы да әле ул. Кечкенә районның проблемалары да аз аның. Әйтик, күрше Теләчедә асфальт кермәгән авыллар калмады. Ә бездә бар әле. Уңай ягы – бездә җир күп. Соңгы вакытта аның да кадере артты. Хәзер кеше җиргә якынайды. Буш ятучы җирләр азаеп бара.

:: Җир дигәннән, халыкны авылларда, районда калдырып буламы? Сер түгел, Мамадыш районында читкә китеп эшләүчеләр дә шактый. Кадрлар мәсьәләсен ничек хәл итәсез?
– Мамадыш зур шәһәрләргә якын урнашкан. Элек-электән безнең халык, КамАЗ төзелгәндә дә, Түбән Каманы төзегәндә дә чыгып китеп, читтә бәхетен тапкан. Ул чакта эшкә килгән кешегә бушлай фатирлар да бирелгән. Без дә яшьләрне читкә җибәрмәс өчен тырышабыз. Мамадышта яңа йортлар сафка баса, ипотека программалары эшли. Эш белән тәэмин итү проблемасын районыбыз эшмәкәре Рифат Мотыйгуллин ярдәме белән хәл итәбез. Ул җитәкләгән «Продпрограмма» агрофирмасында эш урыннары бар. Быел сыр җитештерү заводын зурайтып, анда 20 эш урыны булдырды. Әле тагын «Нократ» сәнәгать паркында яңа заводлар төзелеп килә. Шулай ук кече, урта бизнесны җәелдермәкче булабыз. Үз эшен башлаучыларга ярдәм кулы сузарга әзербез. Каядыр барып эшләргә теләгән кешене тотып калып булмый.

:: Авыллар бетә, дибез. Аларны ничек сакларга соң?
– Анда яшәүче халык өчен эшләү мөмкинлеге тудырырга кирәк. Үз эшен башлаучыларга ярдәм кулы сузарга, кече һәм урта бизнесны үстерү өчен берни кызганмаска, шунда авылларны да, эшче көчләрне дә саклап калып булачак. Безнең Татарстанның икътисады нык. Россиядә 85 субъект бар. Әгәр барысы да яхшы эшләсә, без бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә, пенсионерларга акчаны өч тапкыр күбәйтеп түли алыр идек. Авыл хуҗалыгына тагын да йөз белән борылып, илнең икътисадын күтәрергә кирәк. Халык әйбәт яшәсен өчен, бюджетка гел акча кереп торырга тиеш. Нинди генә эшкә тотынсак та, хөкүмәт ярдәменнән башка булмый. Укып бетергән студентларга ярдәм ит, эшен башласын! Бездә халык бик тырыш. Читтән кертелми дип тормыйк, эшләп күрсәтик. Тегә дә беләбез без, кирәк икән тракторын да җыябыз.

:: Соңгы вакытта туристларны җәлеп итү дә җиңел түгел. Татарстанда матур җирләр күп бит. Мамадыш аларны ничек итеп үзенә тарта?
– Безгә Аллаһы Тәгалә үзе зур мөмкинлек биргән. Мамадыш сулыкларга бик бай. Ике елга – Нократ һәм Чулман ярларында урнашканбыз. Ничек инде шул килеш эшләми утырасың, ди? Быел Нократ яр буена бассейн ясап куйдык. Ул апрельдә ачылган иде, ноябрьгә кадәр кешеләрне кабул итәчәк әле. Чөнки ул бассейннар җылытыла. Аннары шунда ук мунча, хамам, тоз бүлмәләре бар, теләгән кешегә салкын суда коену мөмкинлеге дә тудырылган. Бассейнны бик яраттылар. Әллә кайлардан: Кукмара, Теләче, Саба, Алабуга, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләреннән, күрше Киров өлкәсеннән, Башкортстаннан да киләләр. Без моңа шат кына. Якын киләчәктә чаңгы тавы төзеячәкбез. Әле тагын да кызыклырак ял итү урыннары булдырачакбыз. Зип-Лайн төзергә планнаштырабыз. Ул яшьләргә ошар, дип уйлыйм. Татарстанда әле мондый әйбернең булганы юк. Экстрим булачак анда, 500 метр җир астына аркан белән төшеп китәчәкләр. Барысын да әйтеп бетерми торыйк әле.

:: Нинди генә эшкә тотынсак та, акчасыз булмый. Сез бу эшләрне нинди программалар ярдәмендә башкарасыз?
– Бездә дәүләт программалары яхшы эшли. 2013 елдан бирле бик күп төрле федераль, республика программалары ярдәме белән грантлар отып килдек. Әмма кайчакта баш тулы идея, кесәдә бер тиен акча булмаган чаклар да бар. Әнә шул вакытта хакимияттә эшләүче хезмәттәшләр белән Мамадышны бергәләп матурларга тотынабыз. Читтәрәк урнашкан урамнар, яр буйларын бүлеп алабыз. Кем ничек булдыра, шулай эшли. Махсус программаларда катнашучылар, бәйгеләрдә җиңүчеләр дә булды. Эшкә тотынсаң, акча табыла ул. Мин гел әйтәм: күз курка, кул эшли. Мәчет-чиркәү эшләре дә шулай. Аллаһы Тәгалә әллә кайлардан җаен биреп, ярдәм китереп чыгара.

:: Сез – дингә ихтирамлы кеше. Бервакыт мәктәпләрдә укучы балаларга, әхлак-тәрбия турында китаплар өләшкән идегез. Ул чакта сезне аңлап та бетермәүчеләр булды. Ә бит динне хөрмәтләүнең асылы башкада, минемчә...
– Дөрестән дә шулай. Безнең республикада төрле милләт вәкилләре дус-тату яши. Монда ил җитәкчеләренең өлеше зур. Чит илдән килүчеләрнең күбесе шаккатып китә. Ничек инде мәчетләр янында чиркәү тора сезнең, диләр. Ә бит тыныч тормышның нигезе – татулык. Нинди милләт кешесе булуына карамастан, без аңлашып яшәргә тиеш. Эчкәрәк кереп уйласак, нинди генә диндә булсак та, нинди телдә сөйләшсәк тә, без – Адәм белән Һавадан барлыкка килгән Аллаһ балалары. Дуслык булса, сугышлар да килеп чыкмас иде. Без үсеп килүче яшь буынны дөрес тәрбияләргә тиеш. Шуны күз уңында тотып, быел Соколка авылында мөселман һәм христиан балалары өчен җәйге дини лагерь эшләде. Мөселманнар иртән торып намаз укыды, христианнар дога өйрәнде. Иң мөһиме – балалар Аллаһы Тәгаләне белеп үсәргә тиеш. Шушы лагерьны республика күләмендә дә оештырасы иде.

:: Сез – үз якташларын барлап, санлап, якын итеп торган җитәкчеләрнең берсе. Башка шәһәрләрдә яшәүче мамадышлыларны бер учка җыю авыр түгелме?
– Һәр кеше үз туган җире белән горурланырга тиеш. Кендек каны безнең җирдә тамган кешеләр кайда гына эшләсәләр дә, бу бит – Мамадышныкы, дип горурланабыз. Алар да шулай ди торгандыр. Без якташларны Сабан туе бәйрәменә, Питрауга, Шәһәр көненә чакырабыз. Чаллы, Түбән Кама, Казан шәһәрләрендә якташлык җәмгыятьләре эшли. Мамадыштан чыккан, аның данын еракларга җибәргән һәркемгә рәхмәтлебез.

Әңгәмәдәш – Гөлгенә ШИҺАПОВА

Татар телендә бастырырга иде

Минем кулымда – профессор Индус Таһировның «Воспоминания» китабы. Анда авторның шәхси тормышына, иҗтимагый, рухи яшәешебезгә мөнәсәбәтле шактый гына фоторәсемнәр, документ-материаллар да бар. Киң катлау укучылар да аңларлык үтемле тел белән язылган. Кызыклы, гыйбрәтле эпизодлар, факт-мәгълүмат та күп.

Күрер күзгә кечкенә генә гәүдәле бу кеше эш-гамәлләре белән көчле рухлы, Алыптай батыр зат рәвешендә күзаллана. Илебездә ике гасыр аралыгында булган сәяси-иҗтимагый вазгыять, Мәскәү һәм Казан Кремльләре арасындагы катлаулы, вакыты-вакыты белән бик тә киеренке мөнәсәбәтләр киң катлау укучыларны дулкынландырырлык, уйландырырлык итеп бәян ителә. Бу драматик процессның үзәгендә кайнаган Минтимер Шәймиев, Фәрит Мөхәммәтшин кебек төп фигураларга шактый тулы характеристика бирелә.

Милли-демократик хәрәкәт дулкынында 1992 елда барлыкка килгән Бөтендөнья татар конгрессы турындагы бүлекләрдә бу оешманың татар халкын барлауда, туплауда һәм оештырудагы күпкырлы һәм игелекле эш-гамәлләре турыдан-туры да, аерым шәхесләр эшчәнлеге аша да шактый җентекле яктыртыла.

Мәгълүм ки, соңгы вакытта, бигрәк тә 2022 елда һәм илдә, һәм халыкара масштабта иҗтимагый-сәяси, икътисади тормыш аеруча катлауланып китте. Милли мөнәсәбәтләрдә, бигрәк тә милли мәгариф өлкәсендә проблемалар җитәрлек. Аларны хәл итү тәҗрибә таләп итә. Бу җәһәттән Индус Таһиров китабы укучының тарихи һәм сәяси офыкларын киңәйтәчәк, үткәннәрдән гыйбрәт, сабак алып, нәтиҗәле эш-гамәлләр кылырга булышачак.

Индус Таһиров – бай һәм катлаулы тормыш юлын узган олуг шәхес. Соңгы ярты гасырда Татарстанда, татар дөньясында гына түгел, ә ил күләмендә, халыкара мәйданда да шактый танылды. Ул – күренекле тарихчы, сәясәтче, остаз-педагог, җәмәгать эшлеклесе, профессор, академик. Аның балалык һәм үсмер, мәктәптә уку еллары Шөгер, Түбән Чыршылы, Әлмәт кебек билгеле кала-салаларда уза. Әнисе Әминә Каюм кызы – укытучы, мәктәп директоры, мәгариф бүлеге хезмәткәре. Әтисе Ризак Шәйхетдин улы – авыл советы рәисе һәм колхоз җитәкчесе. Бөек Ватан сугышы башлангач, хәрби хезмәткә алына. Рота белән командалык иткән өлкән лейтенант дәрәҗәсендә 1944 елның ноябрендә һәлак була, Латвия туфрагында җирләнә. Әтисез калган өч бала әниләре тәрбиясендә үсә. Шунысы гаҗәп: аларның икесе дә зур галим буларак танылa. Индус әфәнденең энесе Энгель Таһиров – шулай ук тарих фәннәре докторы, профессор, академик, җәмәгать эшлеклесе.

Индус Ризак улының соңгы 60 елдан артык гомере, хәрби хезмәт чорын исәпкә алмаганда, Казанга бәйле. Казан университетының тарих-филология факультеты студенты, алга таба шушы уку йортының аспиранты, укытучысы. Диссертация яклап, «тарих фәннәре докторы» дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. Тарих факультеты деканы, Ватан тарихы кафедрасы мөдире. 30 елдан артык докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советы рәисе була. Ун ел буена Бөтендөнья татар конгрессын җитәкли. Күпсанлы гыйльми басмалар, монография-җыентыклар авторы. Аларның шактые XX йөздәге ил тарихын, Октябрь инкыйлабын, милли революцион хәрәкәт тематикасын яктыртуга багышланган.

Фәнни-теоретик яктан бик тә әзерлекле, милли-азатлык тарихыннан яхшы хәбәрдар Индус Таһиров илдәге үзгәртеп кору хәрәкәтенең, демократия өчен көрәшнең алгы сафында булды. Берничә мәртәбә Татарстан парламентына депутат итеп сайланды, җөмһүриятебезнең, халкыбызның хокуклары, мәнфәгатьләре өчен фидакарьләрчә эш-гамәлләр кылуның күркәм бер үрнәге булды. Шунысы мөһим: ул бу юнәлештәге эшчәнлеген хәзер дә дәвам иттерә. Аның матбугаттагы, радио-телевидениедәге, электрон чаралардагы, төрле конференция-җыелышлардагы чыгышлары һәрчак зур кызыксыну белән кабул ителә.

«Воспоминания» китабында хатирә-истәлекләр, уйлануларның әле бер өлеше генә теркәлгән. Аны тагын да тулыландырып, камилләштереп, үзебезнең газиз татар телендә дә бастырырга иде.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы, КФУ профессоры

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Гыйләҗев** Дамир Рашат улы; Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Татар Кандызы авыл җирлеге башлыгы **Насыйбуллин** Мәхмүт Шәйхулла улы; халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Чистайның «Раздолье» дәвалау-савыктыру комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Дияров** Шамил Камил улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Әкият» татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесенең курчак уйнатучы артисты **Егорова** Наталия Константиновна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны **Зарипов** Ринат Габделхәй улы; мәдәният һәм сәнгать үсешенә зур өлеш кертүләре, күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кна вел» халык ансамбле хормейстеры **Искаков** Леонид Александрович; Татарстан Республикасы «Агыйдел» җыр һәм бию ансамбле» дәүләт автоном мәдәният учреждениесе директоры **Ялалова** Лилия Мәүләви кызы; тышкы финанс контроле системасын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасының юридик бүлеге башлыгы **Козина** София Александровна; торак-коммуналь хуҗалык тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Коммунсервис-Актаныш» җитештерү берләшмәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Кустова** Римма Зыя кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, әтисе
Мөдәррис Мансур улы БОХАРОВның
вакытсыз вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге баш консультанты Ләйсән Мөдәррис кызы Исламованың авыр кайгысын уртаклаша.

Мин кулыма китап алам

ҮЗЕМ ТҮЛӘРМЕН

«Әгәр Ходай кешегә язучылык таланты биргән икән, ул милләткә хезмәт итәргә, халкы өчен яшәргә һәм иҗат итәргә бурычлы», – ди бер танышым. Һәм халыкка хезмәт итү фәлсәфәсенә бирелә. Мин елмаям. Яшь чакта миллион тапкыр күргән лозунг күз алдына килә: «Партия и народ едины!» Моңсу. Чөнки бу сүзләрне адым саен ишетергә туры килә: «Язучы халыкка хезмәт итәргә... язучы милләткә... язучы бурычлы... язучының төп бурычы...»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Нинди бурыч соң инде ул?.. Мәңге бетми торган...

Менә мин гомер буе яздым. Җыр текстлары, шигырьләр, юморескалар, хикәяләр, повестьлар, романнар... Күп яздым инде, кайбер эстрада йолдызлары минем шигырьләргә язылган җырлардан гына да бер-ике концерт куя ала. Кайберләренә «иде» дип әйтергә дә мөмкиндер, чөнки арабыздан вакытсыз китеп бардылар. Хәния Фәрхи, мәсәлән. Әле исән булганнарының да Нәфкать Нигъмәтуллин, Айдар Галимов, Ризван Хәкимов, Җәвит Шакиров, Альбина Хәкимова һ.б. кебекләре бар. Җыр текстлары гына язсам да, начар малай түгеллегемне аңлата бугай инде бу. Ну, шуннан соң мин сезгә бурычлы булырга тиешме инде? «Китмик әле яшьлек иленнән», «Авыр чакларны уйлама», «Гомер буйлап барам», «Агымсу» кебегрәк җырлар белән дә мин сезне бәхетле иттем бит инде, димәк, бурычымны түләдем. Бурычым булган булса. Ә сез миңа нәрсә бирдегез инде? Юк, бу сорау кызык өчен генә ул: үз җырлары белән сезне бәхетле иткән кешегезгә сез нәрсә бирдегез? Бәлки, биргәнсездер... Мин сизмәдем. Мин фәлән төрле ипотекалар белән янып, кырык кредиттан алданып, баүга менәргәме, әллә тагын тырышып караргамы, дип өзгәләнеп йөргән чакларда берегез дә юк идегез. Ә бит ул җырларны бомжлардан башлап президентларга кадәр ярата иде. Тик мин авыр хәлгә калган чакларда янымда бер бомж да, бер президент та булмады. Халкым... Кем син – минем «халкым»? Ник юк идең миңа авыр чакта?

Ә мин исән. Ходай җаен бирде. Һәм мин кемгә бурычлымын инде? Бомжгамы, президенткамы, халкымамы?

Мин сезнең арада, сезнең тормыш белән яшим. Үтермим дә, таламыйм да, алдамыйм да. Намус кемдәдер була ала икән, ул иҗатчыда – шагыйрьдә, язучыда була; намус иҗатчының әсәрләрендә генә түгел, ә һәр адымында чагыла. Әгәр иҗатчы намусын үгетли икән, ул көнлекчегә әверелә. Мин сезнең иҗатчыгыз булдым. Халыкныкы инде, бер карасаң... Бомж да, көтүче дә, председатель дә, президент та – шул халыкның бер өлеше генә бит инде. Барысы да бертигез, берсе дә әллә кем түгел – гомерләре бары берәү генә.

Тик мин «халык өчен» дигән сүзне аңлый алмыйм.

«Халык өчен яшәүче»ләргә, «милләт өчен янучы»ларга бераз шикләнеп карарга кирәк. Нәрсәнедер әйтеп бетермиләр алар. Соңгы елларда ишәеп тә киттеләр:

Кемдер халык өчен фәлән катлы
Коттедж сала матур урында.
Кемдер халык өчен фәлән томлык
Китап яза үзе турында...

Безнең түрәләрнең барысы да диярлек халык өчен яши. Шуңа күрә, халык үзе өчен яши алмый. Ә бит чынлыкта, халык үзе өчен үзе яшәргә, үзе өчен үзе коттедж салырга тиеш... Фәлән диңгез янындагы курортларга ул үзе барырга тиеш. Үзе миллиардлар белән эш итәргә тиеш. Халык үзе өчен үзе яшәргә тиеш... Ә бездә аз гына башкачарак: халык үзе өчен үзе эшли, ә аның өчен башкалар яши.

Ну, ярый, Ходай, әйтик, мине язучы итеп яралткан, ди. Һәм мин хезмәт итәргә... Әй, сез бернәрсәне дә буташтырмыйсызмы? Халыкка хезмәт итәргә тиешле кешеләр бүтәнчә атала бит. Аларны Ходай депутаттыр-фәләндер итеп яралткан, халык сайлап куйган... Халыкның хезмәтчеләре халыкның үзеннән дә күбрәк зарплата ала һәм костюм-галстуктан гына кыйммәтле машиналарда йөри. Бер җирдә бернинди хезмәтче алай яшәми. Хуҗасыннан да баерак яшәгән хезмәтче бер илдә дә юк. Алар бездә генә: алар – халыкка хезмәт итүчеләр.

Язучы да халыкка хезмәт итәргә тиеш, диләр...

Халыкка хезмәт итү дигәндә, ни өчендер, бер кеше дә хезмәт хакы турында сүз кузгатмый. Язучы халыкка хезмәт итәргә тиеш – һәм вәссәлам. Димәк, сүз бушлай хезмәт итү турында бара. Моны инде: «Язучы халкы өчен бушка эшләргә бурычлы», – дип аңларга туры килә. Яхшы. Мин риза. Әгәр халкым бөтен акчасын үзенең «зур дәрәҗәле», «зур урында утырган», «абруйлы» бүтән хезмәтчеләренә биреп бетергән икән, каршы килеп булмый. Ярый инде, бушлай хезмәт итәрмен. Ләкин мин дә кайбер нәрсәләрдән бушлай файдаланырга тиеш. Кибетләрдән, мәсәлән... Рестораннардан...

Менә монда инде газиз халкымның күзе маңгаена менә: «Нишләп син!.. Бушлай файдаланырга!..» Кайберәүләр әле мине салым акчасына китап чыгаруда гаепли, халык җилкәсендә утыручы сорыкортка исәпли. Тимим мин сезнең салым акчагызга. Хәзер менә чутлап күрсәтәм. Бер китапның үзкыйммәте йөз сум тирәсенә төшә. Аны, әйтик, ике йөздән саталар. Биш мең данәдән бу биш йөз мең табыш китерә. Шуның йөз мең сум чамасы – минем гонорар. Калган дүрт йөзе – туган халкыма. Шул рәвешле мин халкыма хезмәт тә итәм, аңа акча да түлим. Тик барыбер бурыч һаман бетми. Мин һаман бурычлы. Әйтәм бит, язучыдан да ныграк кимсетелгән, ныграк рәнҗетелгән кеше юк бу илдә. Нигә язучы гына бурычлы соң ул?

Кемдер кием тегә. Кемдер машина ясый. Кемдер җыр сүзләре яза. Нәтиҗәдә, без затлы киенеп, ару гына машинага утырып, матур җыр тыңлап барабыз. Кием тегүче дә, машина ясаучы да, җыр язучы да. Өчебез дә бер үк хәлдә. Ләкин монда да иң кимсетелгән кеше – мин, язучы. Чөнки сез теккән киемне дә, сез ясаган машинаны да мин интернеттан «скачивать» итмим, ә сатып алам. Сезнең эшегезне мин акча белән хөрмәт итәм, ә сез – юк. Сез минем хезмәт җимешемне урлап аласыз. Урлар мөмкинлегегез булмаганда, хурларга тотынасыз. «Вәт, үз җырын (китабын, картинасын, киносын) фәлән сумга куйган. И, бигрәк акча ярата инде, кабахәт...» – дисез. Мин дәшмим. Мин бит бурычлымын сезгә. Ни өчендер. Ә ни өчен? Белмим...

Менә фәлән авылда Мөхәммәтәмин тавык үрчетә. Тавыкны аны бөтен кеше дә үстерә ала. Аның өчен бернинди талант кирәкми. Хәтта белем дә, уйлау сәләте дә... Ягъни аның өчен бернәрсә дә кирәкми. Бөтен кеше дә китап яза алмый. Иң гади халык шул китапларны укый, шигырьләрне ятлый, җырларны тыңлый, үзе җырлап юаныч ала. Мин язган шигырьләр белән иң зур җитәкчеләрне котлыйлар. Тавык белән котлаган кеше юк аларны. Дөрес тә булмас иде, патшаларча түгел.

Вәт, шул Мөхәммәтәмин илнең теләсә нинди китапханәсенә кереп, мин язган китапны бушлай укып чыга. Ә мин, дөньяның бер ашханәсенә кереп, ул үстергән тавыкны бушлай ашап чыга алмыйм. Югыйсә хәтта килолап үлчәсәң дә, минем китапның бәясе кыйммәтрәк тора бит инде. Һәм шул Мөхәммәтәмин беркемгә дә бурычлы түгел, ә язучы бурычлы...

Бу күпсенеп әйтү түгел, халкым. Ходай биргән талант өчен синең алдыңда гаепле икәнемне дә, бурычлы икәнемне дә аңлыйм. Тик аны гел искә төшереп торма, яме. Ә иң яхшысы... Иң яхшысы, син конкрет сумманы әйт. Мин түләрмен. Мин әле тагын әллә күпме һөнәр беләм, әллә күпме урыннарда эшлим... Сиңа язучылар гына бурычлы бит... Бүтән беркемнең дә бурычы юк... Мин... түләрмен...

Бездән бурыч калмас.

Марат КӘБИРОВ

Спорт

Исем өчен очко бирмиләр

«Рубин» икенче матч рәттән очрашу ахырында җиңүне кулдан ычкындыра. Шул рәвешле Казан командасы турнир таблицасында Чаллы гына түгел, Түбән Камадан да артты калды. Баш тренер Леонид Слуцкий исә хөкемдарлардан һәм уенчылар җитмәүдән зарлана.

«Рубин» белән «Алания» арасындагы матч алдыннан тамашачы янә Казан командасының премьер-лигада уйнаган, алай гына түгел, Европаны шаулаткан вакытларын искә төшереп моңсуланды. Татарстан башкаласына Алехандро Домингес кунакка килде. Казанда туп типкәндә командасы белән чемпион булып танылган, 2009 елда «Илнең иң яхшы футболчысы» исеменә лаек булган Аргентина уенчысын әле дә сагынып искә алалар. Матч башланыр алдыннан, аның култамгасын алырга дип, йөзләгән кеше чиратка басты. Бүгенге «Рубин»да андый кеше юк.

«Бирегә килгәч, кабат өйгә кайткандай булдым. Казанда да, Санкт-Петербургта да узган гомеремне сагынып искә алам. Монда да, тегендә дә миңа карата яхшы мөнәсәбәттә булдылар. Бүген дә зурлап каршы алдылар. Әлбәттә, бик шатландым», – диде ул матчтан соң узган матбугат очрашуында. Домингес Казаннан киткәч, үзен берничә мәртәбә кабат «Рубин»га чакыруларын да әйтте. «Корбан Бәрдыев («Рубин»ның элеккеге тренеры. – **Ред.**) 2012 елда Аргентинага килгән иде, Казанга чакырды. Ул вакытта мин уйнаган «Ривер Плейт» икенче лигада чыгыш ясый иде. Шуңа күрә ташлап китә алмадым. Казанга һәрвакыт чакырып тордылар. Әмма мин уйнаган командада авыр вакытлар булганга, берсендә дә ризалык бирә алмадым», – диде Алехандро Домингес. Хәзер ул Аргентина телевидениесендә футбол белгече булып эшли. Аңлашылганча, «Рубин»дагы хәлләрне күзәтеп бара. Казан командасының элеккеге уенчылары белән дә аралашып тора. «Команданың премьер-лигадан төшеп калуын авыр кичердек. Без, элек биредә уйнаган футболчылар, аңа ярдәм итәргә тиеш. «Рубин»га безнең теләктәшлек кирәк», – ди Алехандро Домингес.

Очрашуның беренче таймында Домингес та, башкалар да матур уен күреп сөенә алмады. Командаларның берсе дә капкачыларны артык борчымады. Икенче тайм башланугa, «Рубин» алга чыкты. Башта Виталий Лисакович туп кертте, 15 минут узгач, Илья Самошников исәпне 2:0 ясады. Узган атнада Самошниковны «Динамо»га озатканнар иде. Интернетта аның хәтта Мәскәү командасы формасы киеп төшкән рәсемнәре дә пәйда булды. Аннары сәер хәлләр башланды. Имеш, Самошников медицина тикшерүе уза алмаган. Бу хакта рәсми хәбәр булмады. Килешү имзаланмауны исә акча аркасында дип аңлаттылар. «Рубин»ның күбрәккә сатасы, «Динамо»ның исә очсызракка аласы килгән, янәсе. Ничек кенә булмасын, «Алания»гә каршы узган очрашуда 24 яшьлек уенчы иң яхшы футболчыларның берсе булып танылды.

Бу очрашу шул рәвешле тәмамланса, Казан командасы турнир таблицасында икенче урынга күтәрелеп, беренче урында баручы «КАМАЗ» белән ике арада нибары ике очко аерма калачак иде. Ләкин матч ахырында уенның асты өскә килде. Башта хөкемдар Алексей Сухов «Рубин» капкасына пенальти билгеләде. Кунаклар бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмады. Тагын алты минуттан «Алания» исәпне тигезли алды. Бу инде Владикавказ командасы өчен җиңүгә тиң булды. Шул рәвешле, «Рубин», ике очрашу рәттән уен ахырында җиңүне кулдан ычкындырып, 4 очкодан колак какты. Бу юлы баш тренер Леонид Слуцкийның да сабырлыгы төкәнде.

– Әлеге көлке пенальтига кадәр өстенлек тулысынча безнең якта иде. Көндәшнең бер мөмкинлеге дә булмады. Алдагы очрашуда хөкемдар көндәш команда футболчысы Горбуновны уеннан куып чыгарырга тиеш иде. Эксперт-хөкемдарлык комиссиясе әнә шундый карар чыгарды. Бу юлы безнең капкага уйлап чыгарылган пенальти билгеләделәр. Аңлашыла инде, бу вакытта исәп безнең файдага һәм нәтиҗәне саклап калырга тиеш идек. Әмма көндәшкә шундый өстенлек бирелә икән, бу бернинди кысага да сыймый. Барысы да әнә шуннан башланды, – диде Слуцкий.

Баш тренер команданың төп сакчыларсыз калуыннан да зарланып алды. Анысы да хак. Тик команда икенче матч рәттән очрашу ахырында җиңүне кулдан ычкындыра икән, башка сәбәпләрен эзләп табарга кирәк. Беренче лигада беркем дә мондый состав белән мактана алмый. Әле узган атнада гына «Рубин» элегрәк Слуцкий кулы астында ЦСКАда туп типкән Алан Дзагоев белән килешү төзеде. Башкалар мондый уенчылар турында хыяллана да алмый. Аның каравы, очко җыялар. «КАМАЗ»ның беренче урында баруына башта гаҗәпләнсәк, хәзер инде ияләшеп киләбез. Рәттән өч җиңү яулап, «Нефтехимик» та дүртенче урынга күтәрелде. Ә «Рубин» Татарстан командалары арасында иң көчсезе булып чыга.

	Команда	очко
1	КАМАЗ	18
2	Алания Владикавказ	15
3	Балтика	15
4	Нефтехимик	14
5	Рубин	13
6	Арсенал	13
7	Динамо	13
8	Енисей	13
9	Волгарь	12
10	Краснодар-2	10
11	Велес	9
12	СКА-Хабаровск	9
13	Шинник	8
14	Кубань	8
15	Уфа	8
16	Родина	6
17	Акрон	5
18	Волга Ульян	4

rubin-kazan.ru

Сертификат специалиста А №130544, выданный КМК на имя **Гайнуллиной Фаузии Гаптулловны,** считать недействительным, в связи с утерей.

ЧИЯЛЕКНЕҢ – ҮЗ ТӘМЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Аның бакчасында 300ләп үсемлек һәм куак үсә. Унике йортлы Чиялек авылында яшәүче Кәрим абый Хәбиевнең туган нигезе яшел бишекне хәтерләтә. Авылга килүчеләр аның бакчасын күрми китми. Колак ишетмәгән, күз күрмәгән үсемлекләр үсә монда. Кәрим абыйның хыялы – күрше-тирә авыллардагы балаларда табигатькә карата кызыксыну уяту.

Актаныш районында ике Чиялек авылы бар. Икесе дә – кечкенә авыллар. Без барганында 32 йорт булса да, шуның уникесендә нибары 24 кеше яши. Йортлары төзек. Әнә 82 яшьлек Флүсә әби, чалгы тотып, койма буйларын чабып йөри. Һәр йортның капка төбеннән үк чисталык башлана. Безне берәү дә күрми, ишетми дип яшәмиләр, димәк.

– Без үскәндә, авыл шаулап тора иде. Мин беренче сыйныфны тәмамлагач, башлангыч мәктәпне яптылар. Бу чакта авылда өченче сыйныфка кадәр укыган һәм керәсе 47 бала бар иде. Кызганыч, шул мәктәпне бетерделәр. Әнә бүген Байсар мәктәбендә шуның кадәр бала укый, – ди Кәрим абый Хәбиев.

Артыштан башланган...

Кәрим Хәбиев белгечлеге буенча – рәссам, хәзерге вакытта төзүче булып эшли. Читтә эшләсә дә, авылга беркайчан да эзен суытмаган ул. Биш ел элек бакчачылык белән шөгыльләнә башлаган. Анысы да көтмәгәндә генә килеп чыккан.

– Үземне кечкенәдән үсемлекләр ярата торган кеше дип әйтә алмыйм. Әнкәй бәрәңге чүбе утарга кушса, безнең өчен кара кайгы иде инде, – ди бакчачы. – Шәһәргә баргач, бер кибеткә кердем дә бәләкәй генә артыш куагын күреп, шуңа сабый бала кебек гашыйк булдым. Блю Стар төре иде ул. Сатып алып кайтып утырттым. Әмма ул беренче елны ук өшеде. Ничек тәрбиялисен дә, кышка ничек каплыйсын да белмим. Икенче елны тагын шул кибеткә барып, шуны ук сатып алдым. Җәй буе сокланып йөрдем, әмма кышын тагын шундый ук хәл кабатланды. Шуннан соң интернетка кереп, бакчачылык белән кызыксына башладым. Өченчесендә үсеп китте тәки. Хәзер инде ничек тәрбиялисен яхшы беләм.

Шомырт, миләш авылда болай да үсә, ә Кәрим абыйның исә башкаларын үстереп карыйсы килгән. Нарат, чыршы, артышның төрле сортларын күрергә була аның бакчасында. Блю Эрроу, Скайрокет, Рехбраун төрләре, мискантус, гибискус, сәрби куаклары, конторта чикләвеге – ниләр генә юк анда!

Үсемлекләрне күбрәк интернет кибетләрдән, питомниклардан сатып ала икән. «Элек әбиләрдән ала идем. Алар хәзер бозылды, бәяне артык кыйммәтләндерделәр. Моңа кадәр матур чәчкәләрне 50 сумга бирсәләр, бүген шуңа 700–800 сум сорыйлар. Чәчәкләрне интернет аша Голландия, Польшадан кайтартам. Германиядә яшәүче улым: «Әти, сиңа бүләккә нәрсә алып кайтыйм?» – дип сорады. Крейчи мутейшен дигән карагайга (лиственница) кызыгам. Бездә ул бик кыйммәт, бәясе 7 мең сум тора. Анда җиде тапкыр очсызрак. Менә шуны үстереп карыйсым килә», – ди Кәрим абый, хыяллары белән уртаклашып.

Өрәңгесе генә дә – 6–7 мең сум

Санап карасаң, бакчадагы үсемлекләрне сатып алу өчен генә дә 300 мең сум акчасы киткән. Башта хатыны Физүнәдән бәясен яшерә торган булган. Әйтик, Варалло дигән кечкенә чыршысы 4,5 мең сум тора. Иң кыйммәтлесе – 6–7 мең сумлык өрәңге. Ылыслы агачларны яратканга, күбрәк шулар игътибарын җәлеп итә. Артып китсә, башка бакчачыларга да өлеш чыгара. Кайберләре килеп, аннан киңәш тә сорый.

– Бакча шаулап торсын өчен, кимендә 20 ел кирәк. Киләчәктә юллар ясап, яктырткычлар куеп, аны мультфильм геройлары белән бизисем килә. Гаиләм, туганнарым белән ял итү өчен бер урын булачак бу. Шулай ук авыл яшьләрендә авылга, бакчага карата кызыксыну уяту теләгем дә бар, – ди ул.

Әни сүзе – изге сүз...

Рәссам кешегә читтә яшәү өчен мөмкинлекләр аз түгел. Әмма Кәрим абый авылны сайлаган. Аның картиналарын күбрәк Санкт-Петербург, Казанда яшәүчеләр үз иткән. Болар – туган якны яратучылар.

– Армиядән кайткач, авылдан чыгып киттем. Шул вакыт әнкәй: «Улым, мин Свердловскига сеңлем янына кышка яшәргә барам», – диде. Бер кышны чыкты да, шәһәрдә яши алмыйм, кайтасым килә, дип шалтырата. Бу бит инде – миңа да авылга кайтырга дигән сүз. Әнкәй безне, дүрт баланы, авырлык белән ялгыз үстерде. Акыллы, бик тырыш хатын иде. Төпчек бала булгач, мине син карарсың, дип әйтә иде. Менә шул күңелгә сеңеп калган. Кайттым, йорт иске. Шуннан абый белән өй салдык. Элек авылда калучыларга Байсар җирлеге 10 мең данә кирпеч бирә иде. Шуннан бирле авыл дип яшим инде. Хатыным шәһәр кызы булса да, читкә китмәде, – ди ул.

Җиде ел йозаксыз яшәгәнбез...

Читттән караганда Кәрим абый бер дә авыл кешесенә охшамаган. Аңа башкалар да шулай диләр икән.

– Мине авылда, шәһәр кешесе, диләр. Шәһәргә баргач, авыл кешесе, дисәм, ышанмыйлар. Кечкенә авылдан чыккач, кешенең белеме булмый, дип уйлыйлардыр, күрәсең. Китаплар күп укыдым, югары сәнгать кечкенәдән үзенә тартты мине. Кемдер килеп, көтү яки трактор форсункасы турында сөйли икән, ул миңа кызык түгел. Үзем теләгән темага сөйләшүче кирәк. Рок-группа, кино, бакча... Дөрес урында тумаганмындыр, бәлкем, – ди ул, елмаеп.

...Эштән кайткач, бакчага чүп утарга кереп китә Кәрим абый. Физүнә апа: «Ашарга кер», – дип чакырмаса, шунда дөньясын оныта. Күңелгә тынычлык биргән иң рәхәт урын бу, ди. Дөрес, аның да, ник авылдан китмәдек, дип үкенгән чаклары булган. Әмма калага барып, андагы тормышны күреп кайткач, фикере бик тиз үзгәрә икән.

– Авылда кеше эчкерсезрәк, кешелеклерәк. Авылдашларга һәрчак таянып була. Күршеңә дә ышанасың. Өйне салгач, гаиләбез белән каядыр кунакка җыендык. Баксаң, ишекнең биге юк икән. Без шулай җиде ел йозаксыз яшәгәнбез. Монда бер-береңә ышану бар. Бер гаилә булып яшибез, – ди Кәрим абый Хәбиев.

Сәрия МИФТАХОВА

КҮҢЕЛ ЭШЕ

ТАТАРСТАНДА ВОЛОНТЕРЛАР ӨЧЕН БӘЙГЕ БАШЛАНДЫ

Игелекле шөгыль

Алар төрле. Яшьләре, һөнәрләре, билгән вазыйфалары, милләтләре белән аерылалар. Әмма аларның барысын да бетмәс-төкәнмәс ярдәмләшү теләге һәм миһербанлык сыйган олы йөрәк берләштерә. Үзләре турында гел сөйләп йөрмәсәләр дә, аларны күрсәтергә һәм алар үрнәгендә бүтәннәрне дә тәрбияләргә кирәклеге белән берәү дә бәхәсләшмәс.

Татарстанда волонтерлык юнәлешендәге «Игелекле Татарстан» республикакүләм бәйгесенә гаризалар кабул итү башланды. Конкурс үзе берничә этаптан торачак. Аның үзенчәлекләре турында журналистларга сөйләделәр.

Татарстанның яшьләр эшләре министры урынбасары Алла Кондратьева әйтүенчә, бу бәйге 5 декабрь – Россиядә волонтерлар көне алдыннан үткәрелә. Ул «Без бергә» Бөтенроссия премиясенең игезәге сыман. Татарстанда уза торганы да волонтерлык хәрәкәтендә актив катнашучыларны бүләкләү, аларны танытуга йөз тота. Ә Татарстанда соңгы елларда волонтерлык юнәлешләре дә артты, хәрәкәт үзе дә шактый киңәйде.

– «Игелекле Татарстан» бәйгесен тәүге тапкыр 2021 елда уздырдык. 18 төрле номинациядә 38 лауреат, 18 җиңүче бүләкләнде. Татарстанның 45 районыннан барлыгы 273 кеше катнашты, – дип аңлатты Алла Кондратьева. – Шунысы да бар: премиядәге һәр юнәлешне билгеле бер министрлык-ведомство үз канаты астына ала. Әйтик, туристик юнәлештәге волонтер икән, аны Туризм буенча дәүләт комитеты карый.

«Иреклеләр өчен мәгълүмати ресурс үзәге» оешмасы җитәкчесе Айрат Мөбарәкшин сүзләренчә, бәйге биш этаптан торачак.

– Гаризалар кабул итү башланды инде. Гаризаны электрон рәвештә калдырырга була. Моның өчен «Добро» хезмәтеннән файдаланырга кирәк. Барысы да аңлаешлы һәм уңайлы, – дип аңлатты Айрат Мөбарәкшин. – Икенче этап 3 октябрьдән башлап 14енә кадәр дәвам итәчәк. Бу этапта гаризаларны тикшерү булачак һәм бәйгенең киләсе этабына узган катнашучыларның исемлеге игълан ителәчәк. Өченче этап 15–19 октябрь көннәрендә узачак. Катнашучылар социаль челтәрләрдә волонтерлык тормышы турында сөйләргә, уртаклашырга тиеш була. Моның өчен аларга баллар куела. 22 октябрьдән 11 ноябрьгә кадәр конкурсның дүртенче этабы башланачак. Бу этапта катнашучылар жюри әгъзаларына үзләрен тәкъдим итәчәк. Бишенче этап – иң көтеп алынганы. Бу көнне бәйге җиңүчеләре билгеле булачак, ел волонтерының исемен беләчәкбез. Тантана 24 ноябрьдә узачак.

«Игелекле Татарстан» бәйгесендә кемнәр көч сынаша ала соң? Айрат Мөбарәкшин аңлатканча, конкурста аерым волонтерлар да, оешмалар да катнашырга мөмкин.

Лиана Фәйзуллина – әлеге конкурсның былтыргы гран-при иясе – ел волонтеры.

– Катнашкан елымны искә алам да дулкынланып куям. Волонтерларга ел дәвамында башкарган эшләрен күрсәтергә шундый мөмкинлек бирүчеләргә өчен рәхмәт, – ди ул. – Елдан-ел бәйге эчтәлеклерәк, кызыклырак уза. Конкурс волонтерларга үзләрен күрсәтергә, эшебез белән таныштырырга мөмкинлек бирә.

kzn.ru

Волонтерларга гына түгел, алар турында сөйләүче матбугат чараларына да рәхмәт әйтергә телиләр. Шул уңайдан республикада «Добро в эфире» массакүләм матбугат чаралары өчен бәйге оештырыла.

– Былтыр Татарстанда яшәүчеләр арасында сораштыру оештырган идек. Без: «Ни өчен сез волонтерлык хәрәкәтендә катнашмыйсыз?» – дип сорадык. Сораштыруда катнашучыларның 11,6 проценты моны мәгълүмат җитмәү белән аңлатты. Ягъни алар кая, кемгә мөрәҗәгать итәргә, нинди юнәлештә волонтер булырга, нишләргә икәнен белми, – диде Алла Кондратьева. – Шуңа да журналистларның волонтерлык хәрәкәте, үрнәк тарихлар турында сөйләве, язуы, күрсәтүе мөһим.

Былтыр бу конкурста 100дән артык катнашучы булган. Быел да ким булмас дип өметләнәләр. Барлыгы 6 төрле номинация каралган. Журналистлар иң яхшы телесюжет, иң яхшы язма материал, социаль челтәрләрдәге язма һәм башка номинацияләрдә көч сынаша ала. Гомуми приз күләме – 300 мең сум.

Иң мөһиме – башкаларга үрнәк булу, бүтәннәрне дә игелекле эшләр кылырга өндәү, күбрәк кешеләрне җәлеп итү.

Ел волонтеры булып танылу аңа ни биргән соң? Лиана искә алганча, беренче көннәрдә җиңгәненә ышанып бетә алмаган. Җаваплы исем бит! «Һәр яктан игътибар булды. Мондый исемгә лаек булуыма сөендем, әлбәттә. Икенчедән, бу тагын да күбрәк ярдәмләшү, игелекле гамәлләр кылу өчен зур этәргеч булды. Бу исемне аласың да, ул сине ел буе җитәкләп йөри һәм башкарган һәр эшеңне нәрсә өчен башкаруыңны шул вакытта аңлыйсың», – ди җиңүче кыз.

Оештыручылар әйтүенчә, проектларны хуплау, бүләкләү кебек конкурслар күп. «Игелекле Татарстан» исә нәкъ менә шәхесне зурлауга бәйле бәйгеләрнең берсе булып тора.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 329

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+